

## Сәхбетдинова Гөлсинә

## Зәкәрия кызы

Сәхбетдинова Гөлсинә Зәкәрия кызы 1960 елның 8 июнендә Мөслим районы Вәрәшбаш авылында туа. 1968-1974 елларда Вәрәшбаш сигеьеллык мәктәбендә укый. 1974-1976 елларда Мөслим урта мәктәбендә укый. 1977-1982 елларда Казан дәүләт педагогия институтын тәмамлап Мөслим районына эшкә кайта. 1982 елда Яңа Усы сгезьеллык мәктәбендә хезмәт юлын башлап җибәрә. 1998 елда Вәрәшбаш тулы булмаган урта мәктәбенә татар теле һәм әдәбияты укытучы итеп билгеләнә. Башта укыту-тәрбия эшләре буенча завуч, соңрак директор вазифаларын башкара. 2016 елда лаеклы ялга чыга.

***(Хәсәнова Миләүшәнең язмасыннан өзек)***

Сәхбетдинова Г.З. югары категорияле татар теле һәм әдәбияты укытучысы. Эш стажы 33 ел. Гөлсинә Зәкәровна үз фәненә чын күңелдән бирелгән, таләпчән укытучы. Шуңа күрә дә аның укучылары ел саен татар теленнән фән олимпиадаларында, фәнни-гамәли конференцияләрдә, конкурсларда катнашып призлы урыннар яулыйлар. Укытучыларның статусын күтәрү өчен күп санлы проектларда, грантларда катнашабыз. 2014 елда Гөлсинә Закаровна “Иң яхшы укытучы” грантында катнашып җиңү яулады. Яшь буынга белем һәм тәрбия бирү өлкәсендә зур уңышларга ирешкәне өчен 2015 елда район башлыгының Мактау грамотасына лаек булды. Хатын-кыз ул табигатьнең иң гүзәл баласы: ир-атның һавасы, йортның кояшы, тормышның челтерәп аккан чишмәсе, - дип юкка гына әйтмиләрдер. Чыннан да, гүзәл затларыбызның зирәклеге, акылы белән генә тормышны җайлап, дөньяны ямьләп була, ләбаса.

Бу дөньяда иң кыйммәтле нәрсә – кеше гомере. Әле яңа гына мин яшим дип дөньяга аваз саласың, кай арада инде аккан судай гомер үзенең олылыгын дистәләгән еллар белән билгели. Кечкенә чакта һәр туган көнне шатлык-сөенечләр белән көтеп аласың, тизрәк үсәсе, зур буласы килә. Ә еллар узган саен адәм баласы үзенең туган көннәрен сабыррак каршы ала башлый. Артка борылып караган саен узган гомер юллары, истәлекләре күз алдына килә. Узган еллар, үтелгән юллар заяга узмаганлыгы, гомер көзләренә кергәндә җимешләр инде өлгергәнме – менә шуларны әкрен генә барлый башлыйсың. Хатын – кыз исә, бу чорда алдын – артын уйлап акыл белән эш итә, җиде кат үлчәп бер кат кисә.

Бер биргәнгә бирә бит ул Ходай: чибәрлек дисеңме, акыл – тырышлык дисеңме, барысы да артыгы белән ул ханымда. Сүзем Вәрәшбаш төп гомуми белем бирү мәктәбе директоры Сәхбетдинова Гөлсинә Зәкәр кызы турында. Әтисе Зәкәрия абый белән әнисе Лена апаның беренче балалары булып дөньяга аваз сала ул. Кечкенәдән дусларын, ике сеңлесен әйдәп барырга, лидер булырга ярата, һәрвакыт егылганга кул бирергә, мохтаҗларга ярдәм итәргә ашыга. Кешегә үзеңне күрсәтер өчен әллә ни кирәкми: күзгә карап дөресен әйтә белүне зур батырлыкка саныйм мин. Гөлсинә Зәкәровна да шундый, арттан сөйләнеп йөрүне җене сөйми, берәр аңлашылмаучанлык булса, шунда ук ачыклык кертергә тырыша. Мин аңа карап-карап йөрим дә, көнләшеп үк куям: “Бу кеше чыннан да җитәкче булыр өчен туган икән, - дип уйлыйм. Үз кул астында эшләүчеләргә “эш фронты” күрсәтә белү, тыңата алу зур талант бит ул. Гөлсинә Зәкәровна һәр эшнең җиренә җиткерелеп башкарылуын таләп итә. Гомумән әйткәндә, тынгысыз җан.

Гөлсинә апа гаиләсендә дә чын мәгънәсендә бәхетле кеше: тормыш иптәше Заһир абыйның кадерле хатыны, балаларының яраткан әнисе. Инде уллары Рунар белән Илнары гаиләле, малайлардан соң туган алма кебек кызы Алсуы Казан шәһәрендә югары уку йортында укый. “Түтәлене түтәле”- (шүрәлене сөйлә әле) дия-дия өч оныгы үсеп килә. Яшәү яменең асылы гаиләңдә татулык, эш урыныңда яхшылык булса гына күренә шул.